| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**30.08.2019** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1771** |

«2020 елга 2016-2026 елларга «Ишегалды стандарты» муниципаль адреслы программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 26 февралендәге 415 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, шулай ук тулы ял итү өчен уңайлы шартлар тудыру, даими яшәү урынына якын территорияләрдә халыкның югары көнкүреш культурасын, төзекләндерүдә катнашу аша яшәүчеләрдә актив гражданлык позициясен булдыру өчен һәм йорт эчендәге территорияләрдә тәртип булдыру максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Кушымта нигезендә 2020 елга «2016-2026 елларга «Ишегалды стандарты» муниципаль адреслы программасын тормышка ашыруның кыска сроклы планын расларга
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге җитәкчесенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында) http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштыруны тәкъдим итәргә.
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д. А. Сапожников